ГОСУДАРСТВЕННАЯ
ЖИЛИЩНАЯ ИНСПЕКЦИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Б.Красная, 15/9, г.Казань, 420111

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ДӘҮЛӘТ
ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ
Б.Красная ур. 15/9, Казан шәһәре, 420111

тел/факс. 236-91-44. E-mail: tatgi@tatar.ru, сайт: www.gji.tatarstan.ru

№ 111

**П Р И К А З** **Б О Е Р Ы К**

«29» июнь, 2021 ел.

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2018 елның 1 ноябрендәге 435 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе норматив хокукый актын Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2018 елның 1 ноябрендәге 435 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2019 елның 25 декабрендәге 479 номерлы, 2020 елның 3 августындагы 151 номерлы, 2020 елның 16 ноябрендәге 202 номерлы, 2020 елның 17 декабрендәге 221 номерлы, 2021 елның 4 июнендәге 90 номерлы боерыклары керткән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Юридик бүлек җитәкчесенә (Н.Н. Воронская) әлеге боерыкны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Әлеге боерык үтәлешен тикшерүдә тотуны җитәкче урынбасары – хокук идарәсе җитәкчесе В.С.Саттаровка йөкләргә.

Җитәкче С.А. Крайнов

Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясенең 2021 елның «29» июнендәге 111 номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2018 елның 1 ноябрендәге 435 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

2 бүлектә:

2.3 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

а) лицензия бирү турында (лицензия бирүдән баш тарту турында) лицензиатка җибәрелгән (бирелгән) белдерү (әлеге Регламентның 12 нче, 13 нче кушымталары);

б) үзгәртеп рәсмиләштерү турында (үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында) лицензиатка җибәрелгән (бирелгән) белдерү (әлеге Регламентның 14 нче, 15 нче кушымталары);

в) лицензияләр реестрыннан өземтә рәвешендә конкрет лицензия турында белешмәләр, кабул ителгән карар турында ТР Дәүләт торак инспекциясе акты күчермәсен яки сорала торган белешмәләрнең булмавы турында белешмә бирү (әлеге Регламентка 8 нче кушымта);

г) лицензиатка җибәрелгән (бирелгән) лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында белдерү (әлеге Регламентка 16 нчы кушымта);

д) лицензияне озайту (озайтудан баш тарту) турында белдерү (әлеге Регламентка 17 нче, 18 нче кушымталар);

е) лицензияләр реестрында техник хатаны төзәтү турында белдерү (әлеге Регламентка 19 нчы кушымта);

ж) лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү (үзгәрешләр кертү мөмкинлегенең булмавы турында) белдерү (әлеге Регламентка 21 нче, 22 нче кушымталар).

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә ТР ДТИ җитәкчесенең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинетына җибәрелә.

Мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе күпфункцияле үзәктә ТР Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан җибәрелгән, кәгазьдә бастырып чыгарылган, күпфункцияле үзәкнең мөһере һәм күпфункцияле үзәк хезмәткәренең имзасы белән таныкланган электрон документ нөсхәсе формасында алынырга мөмкин.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ яки кәгазь документ нөсхәсе рәвешендә алырга хокуклы.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак, мөрәҗәгать итүче, ихтыярына карап, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен шәхсән ТР Дәүләт торак инспекциясендә кәгазьдә алырга хокуклы.»;

2.4 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасының унөченче һәм ундүртенче абзацында «(лицензия тапшырудан тыш)» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.9 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен дәүләт пошлинасын түләү мөрәҗәгать итүче тарафыннан Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы ярдәмендә алдан тутырылган реквизитлар буенча башкарыла ала.

Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен дәүләт пошлинасын түләгәндә мөрәҗәгать итүчегә түләү документының тутырылган яки өлешчә тутырылган, шулай ук тутырылган түләү документының күчермәсен кәгазьдә бастырып чыгару мөмкинлеге тәэмин ителә.

Түләү документында исәпләмәнең уникаль идентификаторы һәм түләүченең идентификаторы күрсәтелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен дәүләт пошлинасын түләү факты турында мөрәҗәгать итүчегә Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша хәбәр ителә.»;

2.13 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Кирәкле барлык документлар белән гариза алынган көнне.

Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә.

Мөрәҗәгать итүче яки аның вәкиле тарафыннан күпфункцияле үзәк аша бирелгән гариза ТР Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә гариза күпфункцияле үзәктән алынган көнне теркәлә.

Күпфункцияле үзәккә шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, гариза тапшырылган көнне мөрәҗәгать итүчегә гаризаның җибәрелгән булуын раслый торган теркәү номеры һәм электрон гаризаны тапшыру датасы белән Автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан язу бирелә.

Гаризаны Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүче гариза бирелгән көнне Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинетта һәм электрон почта аша гаризаның җибәрелүен раслый торган белдерү ала, анда гаризаның теркәү номеры һәм тапшыру датасы күрсәтелгән була.

ТР Дәүләт торак инспекциясе, мөрәҗәгать итүче тарафыннан мондый документларны яңадан кәгазьдә тапшыру зарурлыгыннан башка гына, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итә һәм гаризаны терки.»;

2.15 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге

редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәтенең һәркемгә күрсәтелә алырлык булуы күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

ТР Дәүләт торак инспекциясе бинасының җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге булган зонада урнашуы;

белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итело торган урыннарның да, кирәкле санда булуы;

дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм вакытлары турында ТР Дәүләт торак инспекциясенең мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендәге мәгълүмат ресурсларында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталында тулы мәгълүмат булуы;

электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;

инвалидларга башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулаган каршылыкларны үтәргә ярдәм итү;

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфаты түбәндәгеләрнең булмавы белән характерлана:

документларны кабул иткәндә һәм мөрәҗәгать итүчеләр аларны тапшырганда чиратлар;

дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын бозулар;

дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт граждан хезмәткәрләре гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр;

дәүләт хезмәтен күрсәткән граждан хезмәткәрләренең мөрәҗәгать итүчеләргә карата дорфа, игътибарсыз мөнәсәбәтенә карата шикаятьләр.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда дәүләт хезмәте күрсәтә торган вазифаи зат белән мөрәҗәгать итүче арасында бер мәртәбә хезмәттәшлек итү күздә тотыла. Хезмәттәшлек итүнең дәвамлылыгы әлеге Регламент белән билгеләнә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан ТР Дәүләт торак инспекциясенең http://www.gji.tatarstan.ru сайтыннан, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан, күпфункцияле үзәк аша алынырга мөмкин.

Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүчегә тиешле гамәл ахырына җиткереп үтәлгәннән соң бер эш көненнән дә артмаган вакытта электрон почта адресына яисә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, рәсми сайт чараларыннан файдаланып җибәрелә.

Мөрәҗәгать итүчеләр өчен Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булуын һәм сыйфатын бәяләү мөмкинлеге тәэмин ителә.

Экстерриториаль принцип һәм комплекслы мөрәҗәгать буенча дәүләт хезмәте күрсәтү гамәлгә ашырылмый.»;

2.16 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче хокуклы:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталында һәм Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә танылканган документларны һәм мәгълүматны Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан файдаланып тапшырырга;

в) электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

д) Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә ТР Дәүләт торак инспекциясе, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә;

е) Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын бәяләргә.

Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Формалаштырылган хисапны форматы-мантыйгы ягыннан тикшерү мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгатьнең электрон формасындагы барлык юлларны тутырганнан соң автомат рәвештә гамәлгә ашырыла. Мөрәҗәгатьнең электрон формасындагы кырлар төгәлсезлекләр белән тутырылган булуы ачыкланган очракта, турыдан-туры мөрәҗәгатьнең электрон формасында мәгълүмат җиткерү юлы белән, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында хәбәр ителә.

Мөрәҗәгать итүчеләрне ТР Дәүләт торак инспекциясенә, күпфункцияле үзәккә кабул итү язу (алга таба – кабул итүгә язу) Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, ТР Дәүләт торак инспекциясе телефоны, күпфункцияле үзәкнең элемтәләр үзәге һәм күпфункцияле үзәктә урнаштырылган электрон чиратны көйләү системасы терминалы аша гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчегә күпфункцияле үзәктә билгеләнгән кабул итү графигы чикләрендә буш булган теләсә нинди кабул итү датасына һәм вакытына язылу мөмкинлеге бирелә.

Билгеле бер датага язылу шушы датага кадәр тәүлек эчендә тәмамлана.

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен, мөрәҗәгать итүчегә система аша соралган мәгълүматларны күрсәтергә кирәк, шул исәптән:

фамилиясен, исемен һәм атасының исемен (булган очракта);

телефон номерын;

электрон почта адресын (ихтыярына карап);

кабул итүнең теләнгән датасын һәм вакытын.

Алдан язылганда мөрәҗәгать итүче күрсәткән белешмәләр мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул иткәндә тапшырылган документларга туры килмәгән очракта, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Алдан язылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә талон-раслама чыгартып алу мөмкинлеге бирелә. Әгәр мөрәҗәгать итүче электрон почта адресын күрсәтсә, күрсәтелгән адреска шулай ук кабул итү датасын, вакытын һәм урынын күрсәтеп, алдан язылуны раслау турында мәгълүмат җибәрелә.

Алдан язылганда билгеләнгән кабул итү вакыты башланганнан соң 15 минут узу белән, ул килмәгән очракта алдан язылуның гамәлдән чыгарылуы турында мөрәҗәгать итүчегә зарури тәртиптә мәгълүмат җиткерелә.

Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта алдан язылудан баш тарта ала.

Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә идентификацияләүне һәм аутентификацияләүне узудан, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен алдан броньлап кую өчен кирәкле вакыт аралыгы озынлыгын исәпләү өчен кирәкле белешмәләр тапшырудан тыш, мөрәҗәгать итүчедән бүтән гамәлләр кылуны таләп итү тыела.».